КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1297

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 ел, 7 август, 674 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 19 апрель, 724-Б номерлы боерыгын тормышка ашыру, шулай ук Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә һәм дәүләт һәм муниципаль функцияләрне үтәгәндә ведомствоара мәгълүмати багланышларны оештыру процессын камилләштерү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 ел, 07 август, 674 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 4 март, 131 нче; 2017 ел, 22 декабрь, 1025 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт

функцияләрен башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин